РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ АМИКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

*423985, ТР, Мөслим районы, ӘМӘКӘЙ авылы, И,Фаррахов ур., 32 йорт*
*Amik.Mus@tatar.ru тел.8(8-5556)3-30-33*

IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXII УТЫРЫШЫ

**КАРАР № 50.**

**Әмәкәй авылы** **16 декабрь 2022 ел**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 24 февралендәге 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Уставы, Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Мөслим муниципаль районының 2022 елның 24 февралендәге 40 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлегендә гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, мәгълүмати стендта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Әмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга (алга таба - Бердәм портал) тиеш.

Бердәм порталда Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат урнаштыру Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле хезмәткәре Әмәкәй авыл җирлегенең вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан һәм Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Вәрәшбаш кабинетын әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) башкарыла.».

1.2. 7 статьяны 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проектын халык алдында тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып, Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге халкы тарафыннан бердәм порталдан файдаланып кертелә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә, Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге халкы шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрә.

Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.».

1.3. 7 статьядагы 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә утырыш рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм Әмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»

2. Әлеге карарны Әмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Әмәкәй авыл җирлеге Советы рәисе** **И.И.Шакирҗанова.**